ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«13» август 2021 ел № 576

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс оештыру турында**

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 октябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү документларын (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган

тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга таләпләрне (2 нче кушымта);
-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын (3 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында хәбәр итү кәгазе формасын (4 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга ачык конкурсның заказчысы итеп Арча муниципаль районы башкарма комитетын, ачык конкурсны оештыручы итеп Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлеген билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрүне 2021 елның 31 декабренә кадәр тәэмин итәргә.

4. Конкурс үткәрү турындагы хәбәр итү кәгазен (4 нче кушымта) Арча муниципаль районының рәсми сайтында (www.arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ә.Галимуллинга йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрүгә**
**КОНКУРС ДОКУМЕНТЛАРЫ**

**Арча, 2016**

ЭЧТӘЛЕК

Кереш
Конкурс шартлары
1.Гомуми белешмәләр
1.1. Сатулар субъектлары һәм конкурс предметы
1.2. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең эчтәлегенә һәм сыйфатына карата гомуми таләпләр
1.3. Шәһәр һәм шәһәр яны пассажир транспорты маршрутларында кулланыла торган автотранспорт чараларына таләпләр
1.4. Конкурста катнашучыларга таләпләр
1.5. Конкурста катнашучылар турында белешмәләр
1.6. Конкурста катнашуга чыгымнар
1.7. Конкурс документларына аңлатма бирү
2. Гаризаларны әзерләү буенча инструкция
2.1. Гаризаны рәсмиләштерү теле
2.2. Катнашучы тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге
2.3. Конкурста катнашуга гариза формаларын тутыруга таләпләр
2.4. Катнашучыларның альтернатив тәкъдимнәре
2.5. Документларны туплау ысулы
2.6. Конвертларны ябыштыру һәм маркалау
2.7. Гаризаларны тапшыру ысуллары һәм соңгы срогы
2.8. Гаризаларда үзгәрешләр һәм аларны кире алу
2.9. Гаризалар салынган конвертларны ачу
2.10. Конфиденциальлекне саклау
3. Конкурска катнаштыру һәм гаризаларны бәяләү
3.1. Конкурска катнаштыру, Катнашучының һәм аның гаризасының конкурс документлары таләпләренә туры килүен билгеләү тәртибе
3.2. Гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру
3.3. Мәгълүмат алу
3.4. Заказчы белән элемтәләр
4. Шартнамә төзү
4.1. Конкурста җиңүчене билгеләү тәртибе
4.2. Конкурста җиңүче дип тану турында хәбәрнамә
4.3. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча шартнамә төзү
4.4. Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты
4.5. Конкурс документларының күчермәләрен алу хокукы. Шикаять бирү хокукы.
Конкурс документларын тутыру формалары
1 нче форма. Конкурска гариза
2 нче форма. Конкурс тәкъдиме
3 нче форма. Конкурста катнашучының анкетасы
4 нче форма. Кадрлар ресурслары турында белешмәләр
5 нче форма. Тәҗрибә: башкарылган эшләр
6 нчы форма. Хәрәкәтчән составны саклау, техник хезмәт күрсәтү, ремонтлау өчен җитештерү-техник база булу турында белешмәләр
7 нче форма. Транспорт чараларына хезмәт күрсәтү өчен җиһазлар булу турында белешмәләр
8 нче форма. Пассажирлар йөртүченең транспорт чаралары турында белешмәләр
**Кушымталар**
1 нче кушымта. Шәһәр яны (муниципаль) автобус маршрутлары буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру һәм гамәлгә ашыру турында шартнамә проекты

## Кереш

Конкурс документлары түбәндәге норматив актлар таләпләре һәм нигезләмәләре нигезендә эшләнде:

Россия Федерациясе Граждан кодексы;

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар ташу, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 94-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 25.07.2005, № 30 (1 өлеш), 3105 б.);

«Автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 08 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Навигация эшчәнлеге турында» 2009 елның 14 февралендәге 22-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 22-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыелмасы, 16.02.2009, № 7, 790 б.);

Россия Федерациясендә инвалидлар хокукларын социаль яклау турында 1995 елның 24 11 декабрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 01 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон;

"Транспорт, техник чараларны һәм спутник навигациясе системасын ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS аппаратурасы белән тәэмин итү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карары (алга таба - 641 номерлы карар) (РФ законнары җыелмасы, 01.09.2008, № 35, 4037 б.).

"ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиешле пассажирлар һәм куркыныч йөкләр ташу өчен кулланыла торган автомобиль транспорт чаралары төрләре исемлеген раслау турында" Россия Федерациясе Транспорт Министрлыгының 2010 елның 9 мартындагы 55 номерлы боерыгы (алга таба - Исемлек) (Россия газетасы, №87, 23.04.2010);

«Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары;

«Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бланкы формасын һәм аны тутыру тәртибен раслау турында» Россия Транспорт Министрлыгының 2015елның 10 ноябрендәге 331 номерлы боерыгы;

«Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең маршрут картасы бланкы формасы һәм аны тутыру тәртибен раслау турында» Россия Транспорт Министрлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 332 номерлы боерыгы;

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 06 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы (алга таба - ТР Президентының ПУ-1115 номерлы Указы);

"ГЛОНАСС+112Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм

системасы турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 22 сентябрендәге 754 номерлы карары (алга таба- ТР МК №754 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 03.11.2010, № 41, 1873 б.);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карары (алга таба - ТР МК №880 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 б.).

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары белән расланган автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж ташу кагыйдәләре.

## 1. Гомуми белешмәләр

### 1.1. Сатулар субъектлары һәм конкурс предметы

Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге даими рәвештә бер яисә берничә муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык алу хокукына ачык конкурс рәвешендә уздырыла торган әлеге сатуларны оештыручы булып тора.

Заказчы - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты.

Билгеле лот буенча конкурста җиңүче булып конкурс комиссиясе бәяләмәсе буенча билгеле лот составына керүче даими рәвештә муниципаль автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру буенча иң яхшы шартлар тәкъдим иткән катнашучы таныла.

Билгеле лот буенча конкурста җиңүче итеп даими рәвештә бер яисә берничә муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар билгеләнергә мөмкин.

Конкурс Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буйлап узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне оештыру хокукын үз эченә алган лотлар (лот) буенча уздырыла.

Конкурс турында хәбәр итү кәгазендә лотларны, шул исәптән маршрутны (беренче һәм соңгы тукталыш пунктларының номерын, исемнәрен), хәрәкәтчән составның санын һәм тибын, килешүнең гамәлдә булу срогын тасвирлау китерелә.

Маршрутлар киселешендә лотлар параметрлары ачык конкурс уздыру турында хәбәр итү кәгазендә бирелде.

### 1.2. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең эчтәлегенә һәм сыйфатына карата гомуми таләпләр

Пассажирлар йөртүче “Юл хәрәкәте иминлеге турында” 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы, “Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында” 2001 елның 08 августындагы 128-ФЗ номерлы, “Автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты Уставы” 2007 елның 8 ноябрендәге 259 номерлы, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, “Автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу ташу кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 01.12.2014 №419-ФЗ Федераль законны исәпкә алып, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, пассажирларны даими маршрутта йөртүне оештыруны һәм гамәлгә ашыруны җайга салучы башка норматив хокукый актлар таләпләрен һичшиксез үтәргә;

маршрутларда эшләү өчен ЮХИДИ органнарында теркәлгән, техник яктан төзек һәм билгеләнгән тәртиптә санитар нормаларга җавап бирүче, лицензияле карточкасы булган, техник карап чыккан гомуми файдаланудагы транспорт чарасы төрләрен хуплау сертификаты булган пассажирларны йөртү өчен билгеләнгән транспорт чараларын кулланырга тиеш.

**1.3. Даими муниципаль автобус маршрутларында кулланыла торган автотранспорт чараларына таләпләр**

Пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен әлеге конкурс документларының 1.1 пункты белән билгеләнгән, аларны чыгару елы, экологик куркынычсызлык (ЕВРО-3 двигателе) таләпләренә туры килә торган һәм түбәндәге параметрларга ия булган үзебезнең һәм чит илләрдә җитештерелгән автотранспорт чаралары кулланылырга мөмкин:

- руль идарәсе уң якта һәм ишекләр сул якта урнашкан;
-түбән идәнле яисә ярымтүбән идәнле;
- ЮХИДИ органнарында теркәлгән;
- билгеләнгән тәртиптә дәүләт техник тикшерүе узган;
- Юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләренә туры китереп тупланган.

Шәһәр маршрут автобусларында кулланыла торган автотранспорт чарасы салонында Килешү һәм ГОСТ 25869-90 шартларына туры китереп, пассажирларга мәгълүмат җиткерү тәэмин ителергә тиеш:

Автотранспорт чаралары визуаль мәгълүмат - маршрутлар схемалары һәм мәгълүмати табличкалар белән җиһазландырылган булырга тиеш (хәрәкәтчән составның маршрутлары күрсәткечләрендә маршрутларның номерлары, башлангыч, соңгы һәм төп арадаш тукталыш пунктларының исемнәре турында мәгълүмат булырга тиеш).

Хәрәкәтчән состав салонында мәгълүмати табличкаларда түбәндәге язмалар яисә символик сурәтләр (пиктограммалар): хәрәкәтчән составның инвентарь номеры; транспорт предприятиесенең адресы һәм телефоны номеры; балалы һәм инвалид пассажирлар өчен урыннар; янгын сүндерү җайланмасы урнашкан урыннар, ашыгыч туктату төймәләре, аптечкалар; хәрәкәтчән составтан файдалану кагыйдәләре; керү һәм чыгу; аларны ачу ысулын күрсәтеп, чыгу урыннары (тәрәзәләр, ишекләр, люклар аша) булырга тиеш.

**1.4. Конкурста катнашучыларга таләпләр**

Конкурста түбәндәге таләпләргә туры килә торган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар катнаша ала:

1. пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булу;
2. даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты реестрында күрсәтелгән таләпләргә туры килү, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык булу, транспорт чаралары милек хокукында яисә башка законлы нигездә булу;
3. ачык конкурста катнашучыны юкка чыгару һәм ачык конкурста катнашучыны банкрот дип тану турында арбитраж судның карары булмау;
4. ачык конкурста катнашучының соңгы хисап чорында бюджетларга мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау;
5. гади ширкәт шартнамәсенең язма рәвештә булуы (гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар өчен)

**1.5. Конкурста катнашу чыгымнары**

Катнашучы конкурста катнашуга гариза әзерләүгә һәм бирүгә бәйле барлык чыгымнарны да үти (алга таба текст буенча - гариза), ә Конкурсны оештыручы әлеге чыгымнарга бәйле рәвештә җаваплылык алмый һәм конкурс нәтиҗәләренә бәйсез рәвештә бурычлары юк. Конкурс документлары Катнашучыга электрон рәвештә бушлай бирелә.

**1.6. Конкурс документларына аңлатма бирү**

Конкурс документлары эчтәлегенә сораулар туганда, Катнашучы Конкурсны оештыручыга конкурс документлары нигезләмәләрен аңлатуны сорап, язма рәвештә мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы. Әгәр мөрәҗәгать Конкурсны оештыручыга конкурста катнашуга гаризалар бирү срогы тәмамланган көнгә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча керсә, Конкурсны оештыручы әлеге мөрәҗәгать кергән көннән алып ике эш көне эчендә конкурс документлары нигезләмәләрен язма рәвештә аңлатырга тиеш.

Конкурс документлары нигезләмәләрен аңлату Катнашучының соравы буенча җибәрелгән көннән алып бер көн эчендә Конкурсны оештыручы тарафыннан сорау предметын күрсәтеп, әмма сорау биргән Катнашучының исемен күрсәтмичә, рәсми сайтка урнаштырылырга мөмкин. Конкурс документлары нигезләмәләрен аңлату аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

## 2. Гаризаларны әзерләү буенча инструкция

**2.1. Гаризаны рәсмиләштерү теле**

Катнашучы әзерләгән гариза, әлеге гариза белән бәйле барлык корреспонденция һәм документлар рус телендә рәсмиләштерелергә тиеш.

Катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән документлар тиешле рәвештә рус теленә тәрҗемә ителгән вариант белән беркетелгән очракта, гариза башка телдә рәсмиләштерелергә мөмкин.

**2.2. Катнашучы тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге**

1. Конкурста катнашуга гариза (1 нче кушымта).
2. Конкурс тәкъдиме (2 нче кушымта).
3. Конкурста катнашучының анкетасы (3 нче кушымта).

а) фирма исеме (атамасы), оештыру-хокукый формасы турында белешмәләр, урнашу урыны турында белешмәләр, почта адресы (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны (физик зат өчен) турында белешмәләр, элемтә өчен телефоны номеры;

б) юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә мондый өземтәнең нотариаль таныкланган күчермәсе (ачык конкурс уздыру турында хәбәр итүнең рәсми сайтында урнаштырылган көнгә кадәр алты айдан да иртәрәк булмаган вакытта алынган булса);

в) заказ урнаштыруда катнашучы юридик зат исеменнән гамәлләр кылуга затның вәкаләтләрен раслый торган документ (физик затны билгеләп кую яки сайлау турында карар күчермәсе яисә физик затны вазифасына билгеләү турында боерык, аның нигезендә мондый физик затның заказны урнаштыруда катнашучы исеменнән ышанычнамәсез эш итү хокукы булу (алга таба - җитәкче). Заказ урнаштыруда катнашучы исеменнән башка зат эш иткән очракта, конкурста катнашуга гаризада шулай ук заказ урнаштыруда катнашучы исеменнән заказ урнаштыруда катнашучы мөһере белән таныкланган һәм заказ урнаштыруда катнашучы яисә әлеге җитәкче тарафыннан имзаланган заказ яисә әлеге ышанычнамәнең нотариаль таныкланган күчермәсе булырга тиеш (юридик затлар өчен) .

г) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә шәхси эшкуар буларак теркәлү турында таныклык күчермәсе.

д) 8 кешедән артыграк сандагы пассажирларны йөртү өчен җиһазланган автомобиль транспортында йөртүгә лицензия күчермәсе.

е) соңгы хисап чоры өчен җитәкче һәм ИФНС тарафыннан таныкланган бухгалтерлык балансы күчермәләре (1 нче форма) һәм табышлар һәм зыян турында хисап (2 нче форма).

ж) Пассажирларны иминиятләштерү шартнамәсе күчермәсе.

4. Кадрлар ресурслары турында белешмәләр (4 нче кушымта).

Белгечләр булуны раслый торган документларның күчермәләре (медицина, машина йөртүче персонал, механиклар).

5. Тәҗрибә: башкарылган эшләр (5 нче кушымта).

6. Хәрәкәтчән составны саклау, техник хезмәт күрсәтү, ремонтлау өчен җитештерү-техник база булу турында белешмәләр (6 нчы кушымта).

7. Транспорт чараларына хезмәт күрсәтү өчен җиһазлар булу турында белешмәләр (7 нче кушымта).

8. Пассажирлар йөртүченең транспорт чаралары турында белешмәләр (8 нче кушымта).

ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсеннән узган хисап елы өчен юл-транспорт һәлакәтләре саны турында белешмәләр; ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппараты ("ГЛОНАСС+112" бердәм дәүләт мәгълүмат системасы) белән җиһазлау турында белешмәләр.

### 2.3. Конкурста катнашуга гариза формаларын тутыруга таләпләр

Гариза формалары төзәтүләрсез, бозуларсыз, аңлаешлы итеп тутырылырга тиеш. Формаларны карандаш белән тутыру тыела.

### 2.4. Катнашучыларның альтернатив тәкъдимнәре

Катнашучылар маршрутта заказчы тарафыннан таләп ителә торган аз сыешлы автобуслар урынына зур яки урта сыешлы автобусларны лот составында куллану турындагы тәкъдим өлешендә генә альтернатив тәкъдимнәр кертә алалар, Катнашучы Шартнамәне үтәгәндә, әлеге маршрут буенча шундый күләмдә автобус һәм рейсларны кулланырга тәкъдим итә, ул хәрәкәтнең даимилеген һәм интервалын тәэмин итәр иде.

Башка альтернатив тәкъдимнәр каралмый.

### 2.5. Документларны туплау ысулы

Катнашучы гаризаны түбәндәгечә әзерләргә тиеш:

1)гаризаның барлык битләренә номер сугылырга, «Прошито, пронумеровано ____ листов, копии документов верны» язмасы булырга, Катнашучының документларны алу, алыштыру яки өстәү мөмкинлеге булмаслык итеп, Катнашучының имзасы һәм мөһере белән беркетелергә тиеш.

2) гаризада документлар түбәндәге тәртиптә урнаштырыла:

1. катнашучы тарафыннан имзаланган конкурста катнашуга гариза (1 нче һәм 2 нче формалар);

2. җитәкченең конкурста катнашуга гаризага  имза салырга хокуклы булуын раслый торган документ (юридик затлар өчен);

3. конкурста катнашуга гаризаны имзалау хокукына ышанычнамә (конкурста катнашуга гаризаны оешма җитәкчесе яисә конкурста катнашучы шәхси эшкуар имзаламаган очракта). Шул ук вакытта шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән ышанычнамә нотариаль таныкланырга тиеш;

4. Катнашучы турында мәгълүмат, шул ук вакытта Катнашучы турында белешмәләрнең беренче документы булып, гаризаны имзалаган зат тарафыннан имзаланган, реквизитларын күрсәтеп, теркәлә торган документларның исемлеге булырга тиеш (исеме, датасы, номеры (булса). Калган барлык документлар исемлектә күрсәтелгән тәртип нигезендә урнаштырыла;

5. Әлеге конкурс документлары таләпләре нигезендә аларның күчермәләрен бирү каралмаган булса, өченче затлар тарафыннан бирелгән документларның төп нөсхәләре тапшырылырга тиеш.

## 2.6. Конвертларны  ябыштыру һәм маркалау

Катнашучылар гаризаны конвертка  салырга һәм конвертны ябыштырырга тиеш. Конверт «Заявка по лоту ______» дигән язу белән билгеләнә.

Конвертта югарыда күрсәтелгән язмалардан тыш түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

- конкурс исеме;
- конкурста катнашучының тулы исеме;
- конкурста катнашучының адресы.

Шул ук вакытта, әгәр Катнашучы берничә лот буенча конкурста катнашса, аларны тәэмин итүле, Катнашучы турында белешмәле  гаризалар төрле конвертларда - һәр лотка берешәр булырга тиеш.

Югарыда күрсәтелгән конверт ябыштырылырга, Катнашучы имзасы һәм мөһере белән беркетелергә тиеш, шул рәвешле, конвертны мөһер һәм катнашучының имзасын бозмыйча гына ачу мөмкинлеге булмаска тиеш.

Шуннан соң "Заявка по лоту_______" конвертын зарарланмаган конвертка тыгып куялар.

Тышкы конвертта түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Конкурсны оештыручыга конвертны җибәрүче затның тулы исеме/фамилиясе, атасының исеме, кире адресы;

- конкурсның исеме һәм адресы;

- конкурс турындагы хәбәр итү кәгазендә урнаштырылган конвертларны ачу вакытын һәм датасын күрсәтеп, " ______________ кадәр ачмаска" сүзләре.

## 2.7. Гаризаларны тапшыру ысулы һәм ахыргы срогы

Катнашучылар Конкурсны оештыручыга гаризалы конвертны тапшырырга яисә әлеге конвертны почта аша җибәрергә хокуклы.

Конкурсны оештыручы кабул ителгән гаризалы конвертларны эзлекле рәвештә язып бара торган гаризаларны теркәү журналы алып бара. Әлеге журналга кергән һәр конверт буенча конвертның керү вакытын һәм датасын, аны тапшыру ысулын (шәхсән

яисә почта аша) күрсәтеп, язма ясала. Әгәр конверт Конкурсны оештыручыга бирелсә, конвертны тапшырган зат журналга язылып куела.

Гаризалы конвертны почта аша җибәргән очракта, ул тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелергә тиеш. Шул ук вакытта Катнашучы, Конкурсны оештыручы конвертны хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән вакыттан да соңга калмыйча алсын өчен, аны алдан җибәрергә тиеш. Конкурсны оештыручы конверт почта аша кирәкле срокта килеп җитмәгән өчен Катнашучы алдында җаваплы түгел.

Конкурс турында хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән сроктан соң алынган барлык гаризалар соңга калган дип санала. Алар кире кагылачак һәм катнашучыга кире кайтарылачак.

### 2.8. Гаризаларда үзгәрешләр һәм аларны кире алу

Гаризаны кире алу турында гариза Конкурсны оештыручыга гаризалы конвертларны ачкан вакыттан соңга калмыйча керергә тиеш.

Үзгәрешләр алдагы гаризаны кире алу һәм әлеге конкурс документларының 2 пункты нигезендә яңасын бирү юлы белән рәсмиләштерелә һәм конкурска тапшырыла.

Аларны бирү вакыты узганнан соң гаризага бернинди үзгәрешләр кертелергә мөмкин түгел.

Гариза кире алынган очракта, аны кире алу турында язма гариза Конкурсны оештыручыга конвертны тапшырган зат яисә почта аша җибәргән зат тарафыннан бирелә. Гаризалы конвертны турыдан-туры Конкурсны оештыручыга тапшырган яки конвертны почта аша җибәргән очракта, бирелгән конвертны алу турында расписка почта аша җибәрү турында хәбәрнамә беркетелә. Конвертны биргәндә, аны алучы зат конвертны кире кайтару турында искәрмә белән журналга имза сала.

### 2.9. Гаризалар салынган конвертларны ачу

Конкурсны уздыру турында хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән көнне, вакытта һәм урында конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста катнашуга гаризалы конвертлар ачыла.

Конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачкан көнне, Конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачар алдыннан, ачык конкурс уздыру һәм конкурс документлары турында хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән вакыттан да иртәрәк булмаган вакытта конкурс комиссиясе Катнашучыларга конкурста катнашуга гариза бирү, үзгәртү яки кире алу мөмкинлеге турында игълан итәргә тиеш. Әлеге абзацта каралган тәртиптә гариза биргән затлар гаризаны үз вакытында биргән дип санала.

Конкурс комиссиясе Конкурсны оештыручыга билгеләнгән вакытта кергән гаризалы конвертларны гына ача.

Конкурс комиссиясе «Заявка по лоту № ____» дигән язулы конвертны һәм тышкы конвертны ача.

Конкурста катнашуга гариза биргән Катнашучылар яисә аларның вәкилләре конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачканда катнашырга хокуклы.

Конвертларны ачканда конкурс комиссиясе түбәндәгеләрне игълан итә: атамасы (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме (физик зат өчен) һәм һәр катнашучының почта адресы, аның конкурста катнашуга гаризалы конверты, тышкы конверттагы конвертлар саны, «Заявка по лоту ___________» конвертында булган документлар барлыгы турындагы белешмәләр. Игълан ителгән мәгълүматлар конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачу беркетмәсенә кертелә. Конвертларны маркалау һәм аларга мөһер сугу әлеге конкурс документларында билгеләнгән критерийларга туры килмәсә, бу хакта белешмәләр шулай ук конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачу беркетмәсенә кертелә. Беркетмәгә конвертларның бөтенлеге бозылу, документларны тегү һәм беркетү таләпләре бозылу, документларны тегү һәм беркетү элементларының бөтенлеге бозылу турында белешмәләр кертелә.

Конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачканда, конкурс комиссиясе конкурста катнашучылардан үзләре тапшырган документларның һәм гаризаларның нигезләмәләрен аңлатуны таләп итәргә хокуклы. Шул ук вакытта конкурста катнашуга гаризаны үзгәртү рөхсәт ителми. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучыларга өстәмә таләпләр куярга хокуксыз. Катнашучыларга карата Конкурс документларында күрсәтелгән таләпләрне үзгәртергә рөхсәт ителми. Күрсәтелгән аңлатмалар конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачу беркетмәсенә кертелә.

Конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачу беркетмәсе конкурс комиссиясе тарафыннан алып барыла, конкурста катнашуга гаризалы конвертларны ачканнан соң ук конкурс комиссиясендә катнашучы барлык әгъзалар тарафыннан имзалана. Күрсәтелгән беркетмәнең күчермәсе Конкурсны оештыручы тарафыннан конкурс турында хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән сайтта урнаштырыла.

Әгәр гаризалы конвертлар хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән датадан соң керсә, әлеге конвертлар ачыла, аларның эчтәлеге күрсәтелгән конвертны җибәргән затка кире кайтарыла.

## 2.10. Конфиденциальлекне саклау

Гаризаларны өйрәнү, бәяләү һәм чагыштыру турында мәгълүмат конкурста катнашучыларга яисә конкурста җиңүче игълан ителгәнчегә кадәр рәсми рәвештә бу процесска катнашы булмаган башка затларга хәбәр ителергә тиеш түгел.

# 3.Конкурста катнаштыру һәм гаризаларны бәяләү

## 3.1. Конкурста катнаштыру. Катнашучының һәм аның гаризасының конкурс документлары таләпләренә туры килүен билгеләү тәртибе

Конвентларны ачу беркетмәсендә күрсәтелгән барлык гаризалар конкурс комиссиясе тарафыннан үз вакытында әлеге конкурс документлары таләпләренә туры килү-килмәү предметына карала.

Конкурста катнашуга гаризаларны карау йомгаклары буенча Катнашучы конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста катнашуга түбәндәге очракларда кертелми:

1) катнашучы тапшырган документлар составында әлеге конкурс документларының 2.2 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларның булмавы яисә мондый документларда катнашучы турында төгәл булмаган белешмәләр булу;

2) катнашучының әлеге конкурс документларының 1.4 п. таләпләренә туры килмәве;

3) конкурс документларын рәсмиләштерүгә таләпләрне бозу, әгәр алар гаризаны дөрес һәм вакытында бәяләүнең мөмкин булмавына китерү;

4) документларны тегү һәм беркетүгә таләпләр бозылу яисә документларны тегү элементларының бөтенлеге бозылу, әгәр бу бозулар конвертларны ачу беркетмәсендә тышкы конвертның бөтенлеген бозу турында тамга ясалган гаризалар буенча булмау;

